ГЛАВА КАНАШСКОГО
СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮГАРЫ ОСЛАН
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ
КАНАШ АВЫЛ
ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

26.10.2021 д. Канаш - №2

Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлегенең
Канаш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм
куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче ст., Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлеге Уставының 24нче статьясына туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2021 нче елның 10 нчы ноябренә Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлегенең Канаш авылында гражданнарның үзара салымын кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлегенең Канаш авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2022 нче елда 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алган акчаларны җирле әһәмияткә ия булган мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?:

«Канаш авылының Үзәк урамы буенча юлга вак таш салу»
«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Канаш авылы, Центральная урамы, 32 нче йорт адресы буенча урнашкан торак йорт янында гражданнар җыенын үткәрергә.

4 Халык җыенын Канаш авыл җирлеге Башкарма комитеты оештыра.

5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Канаш авыл җирлеге башлыгы: Н.Н.Вальков